# ЧИШМӘ БАШЫ



№5 2025ел
март

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

80 ЖИҢҮ!

*Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

**Бу санда:**

- Яз турында шигырь-ләр, сынамышлар
- 8 Март-Хатын-кызлар көне
- Хуш киләсең, Нәүрүз!
- Кошлар кайта!
- Әти - әниләргә язгы чорда куркынычсызлык кагыйдәләре

## -Яз килә -
## Мөнир Мазунов шигыре

*Көннәр аяз, күктән алсу*
*Нур сибеп кояш көлә.*
*Җиргә тама көмеш тамчы –*
*Сагынып көткән яз килә.*

*Әйтегезче, кайсы вакыт*
*Яздагыдан ямьлерәк?*
*Кыш айларын да яратам,*
*Әмма яз күңеллерәк.*

*Көннәр җылы, күктә алсу*
*Нур сибеп кояш көлә, -*
*Җәйге шатлык, күзгә бәхет*
*Яз белән бергә килә.*

## Халык сынамышлары

- *Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.*
- *Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.*
- *Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.*
- *Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.*
- *Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.*
- *Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.*
- *Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.*
- *Яз көне елгаларда су артмаса,ашлык уңмас.*



# 8 Март-Хатын-кызлар көне.



*Хөрмәтле гүзәл затларыбыз !*

Хөрмәтле әниләр, кадерле кызлар! Сезне барыгызны да Халыкара хатын – кызлар бәйрәме – 8 Март белән тәбрик итәбез. Бәйрәмнең кайсы да тәнгә җиңеллек, рәхәтлек, җанга ял алып килә. Шушы бәйрәм көне сезгә, елмаеп балкыган кояш матурлыгын, табигатьнең самимилеген өстәп, күңелләрегезгә шатлык, тәнегезгә саулык, өйләрегезгә иминлек алып килсен. Сезне матур бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Ныклы сәламәтлек, бәхет, якыннарыгызның хөрмәтен һәм сөюен, иминлек, бөтен изге эшләрегездә яңадан-яңа уңышлар телибез.

Яз кояшы елмаеп карап, табигатьнең уяна башлаган мәлендә язның тәүге бәйрәме - Халыкара хатын-кызлар көнен бәйрәм итәбез.

Хатын-кыз - ул кешегә тормыш бүләк итүче, Җир йөзендәге буыннар чылбырын дәвам итүче, гомумкешелек кыйммәтләрен саклап, буыннан-буынга тапшыручы изге зат. Әниләребезнең бер җылы сүзе безнең күңелләребезне күтәрә, бер җылы карашы барлык авырлыкларны юып алгандай юкка чыгара. Хатын-кызлар - гаилә учагын сүндерми саклап тотучылар.

Һәр балалар бакчасында бу яз бәйрәме алдыннан тантаналы чаралар үткәрелә. Безнең балалар бакчасында да Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган иртәнге бәйрәмнәр узды. Әзерлек бәйрәм башланганчы ук башланды. Тәрбиячеләр балалар белән шигырьләр өйрәнделәр, әңгәмәләр үткәрделәр, музыка җитәкчесе белән бергә җырлар, биюләр өйрәнделәр. Яраткан әниләре һәм әбиләре өчен бүләкләр: котлау открыткалары, үз куллары белән ясалган эшләнмәләр әзерләделәр. Төркемнәрне һәм музыка залын бизәү буенча зур эш башкарылды. Бөтен җирдә бәйрәм атмосферасы хөкем сөрә. Балалар иртәнге бәйрәмне көтеп күңелле итеп килделәр. Үзләренең шигырьләре, биюләре, җырлары белән әниләргә бик күп яхшы сүзләр, наз һәм игътибар бүләк иттеләр. Балаларының чыгышларын карап, әниләрнең күбесе елап та җибәрде. Ә кайбер биюләрдә һәм уеннарда олылар сабыйлар белән беррәттән катнаштылар. Әти-әниләр бик канәгать һәм балаларының уңышлары белән горурланалар иде. Бәйрәм рухы катнашучылардан тамашачыларга гаять зур җылылык һәм тантана белән күчте.



## Хуш киләсең, Нәүрүз!

Нәүрүз  – төрки һәм фарсы телле халыкларның бик борынгыдан килгән бәйрәме. Ул 21 мартта көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә.

Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз бәйрәме атна-ун көн дәвам иткән. Фарсыча “Нәү”-яңа, “рүз”- көн дигәнне аңлата. Көнчыгыш календаре буенча бу-Яңа елны каршылау бәйрәме. Нәүрүз бәйрәме – ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу гүзәл, язгы бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер-берсенә булган үпкәләрен оныталар, җырлыйлар , бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы- Нәүрүзбикә. Балалар йорттан - йортка кереп, “нәүрүз әйтеп” йөргәннәр:

Ач ишегең керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер-дога кылабыз,
Нәүрүз мөбәрәкбад!

“Нәүрүз”иң шатлыклы яз бәйрәме-өмет бәйрәме билгеләп үтелгән.Таң ату белән учак кабызганнар.Шул чакта итле аш яки ботка пешереп кешеләр бер-берсен сыйлаганнар.Учак әйләнәсендә балачагалар, кызлар, егетләр әйләнгәннәр.Менә шушы шәрык бәйрәме безнең көннәрдә халык йоласы буларак яңартыла. Бу көнне халкыбыз уйный, ярыша, күңел ача.

Шул уңайдан мәктәпкә әзерлек төркеме белән  “Нәүрүз мөбәрәк булсын! ” дигән музыкаль кичә узды. Балалар 21 мартта билгеләп үтелүче бәйрәмнең тарихы һәм традициясе белән таныштылар, бәйрәм күңелле милли җырлар, биюләр, мәзәкләр һәм гомуми күңел ачу белән үрелеп барды. Балалар Убырлы, Кар кызы һәм Нәүрүзбикә белән бергә «Чума үрдәк,чума каз», «Тамчы там», «Кашыкка йомырка салып йөгерү»,  «Ледянкалар тартып йөрү»,  «Убырлының борыны» уеннарында актив катнаштылар. Шулай ук алар Кар кызының табышмакларына җавап бирделәр, шигырьләр сөйләделәр. Бәйрәм бик күңелле узды.











# Кошлар кайта!



Барлык күчмә кошлар яз көне туган якларына кайталар. Иң элек шуны билгеләп үтәргә кирәк: күпчелек кошларның туган илләренә беренче булып ата кошлар кайта. Бу объектив сәбәпләр белән аңлатыла-оялар төзергә яки яңартырга кирәк. Һәм моның белән нәкъ менә ата кошлар шөгыльләнә. Буынны чыгару – аналарның бурычы-соңрак һәм тиешле шартлар булганда актуальләшә.

Канатлылар өйләренә нинди тәртиптә кайталар соң? Барлык күчмә кошлар да билгеле бер календарь буенча туган якларына кайталар. Һәр гаилә ел саен, көнгә чаклы төгәллек белән туган якларына әйләнеп кайталар .Канатлыларның очышлар эзлеклелеге графигы бар, аның нигезендә язын кайсы кошларның беренче булып килүен ачыкларга мөмкин. Җентекләбрәк карыйк. Җылы яклардан кошларның очып кайту календаре якынча шулайрак күренә:



- Каргалар 18-20 мартта кайта.
- Сыерчыкларның кайтуы 25 марттан 6 апрельгә кадәр эләгә.
- Тургайлар, аккошлар, миләш чыпчыклары 1 апрельдән 10 апрельгә кадәр кайталар.
- Казлар, үрдәкләр, акчарлаклар, торналар 11-20 апрельдә күпләп кайта.
- Апрель азагында уткойрыкларны, урман тимераякларын сәламләргә була.
- Карлыгачлар очрашуы майның беренче яртысында була.
- Сандугачлар кайтуы май урталарына туры килә.

Һәр кошның үз очу графигы гына түгел, ә билгеле бер очу маршруты да бар. Һәр гаилә үзенә хас юл буенча очып йөри.

Әйләнә-тирә мохитне саклау проблемасына балаларның һәм аларның ата-аналарының игътибарын җәлеп итү максатларында балалар бакчасында «Иң яхшы сыерчык оясы» конкурсы үткәрелә.















# Әти - әниләргә язгы чорда куркынычсызлык кагыйдәләре

Барыбыз да зарыгып көткән яз җитте. Көннәр җылына. Җылы кояш нурлары барыбызны да урамга дәшә. Әмма безне урамда бик күп хәвеф-хәтәрләр көтеп тора. Балаларның иминлеген саклау максатыннан, язын урамда дөрес тоту кагыйдәләрен карап китик.



## *Язгы боз өсте*

Язгы кояш нурлары тәэсирендә боз өсте дә юкара. Балаларга язгы бозның ярылып китү куркынычын аңлатырга,  боз өстенә керергә ярамаганлыгын, балык тотарга ярамаганлыгын һәм су өстендә агып баручы боз кисәкләре өстендә сикереп йөрүнең куркыныч икәнлеген төшендерергә кирәк.




## *Боз сөңгеләре*

Өй түбәләрендәге карлар эрү сәбәпле бик озын боз сөңгеләре барлыкка килә. Боз сөңгеләре төшеп  төрле җәрәхәтләр барлыкка килергә мөмкин. Шуңа күрә балаларга боз сөңгеләре асылынып торган урыннардан читтә йөрергә кирәклеген аңлатырга кирәк.



## *Яр кырыйлары*

Күп урыннарда яр кырыйлары текә һәм  биек. Кышын өшегән балчык яр кырыйларын  бик яргалый әгәр дә яр кырыена якын килсәң  язгы кар суына төшеп китү куркынычы бар. Балаларны яр кырыйларында йөрүдән саклыйк!



## *Су басулар*

Язын кар эри башлау белән елгаларда су күләме арта башлый. Ярларыннан ташып чыккан суда йөрергә ярамый. Яр кырыйларына якын килергә ярамый.



## *Гөрләвекләр, җыелып торган сулар*

Яз җитүгә урамнарда  гөрләвекләр ага башлый, күп урыннарда җыелып торган кар суларын очратырга мөмкин.  Ә балалар нәкъ шушы сулар-да уйнарга , кәгазьдән көймәчекләр җибәреп уйнарга яраталар. Кар сулары бик салкын булганлыктан балалар салкын тидерергә мөмкин!

Баш мөхәррир - татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы
Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы